КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 8 апрель г.Казань № 276

Казан шәһәре, Туфан Миңнуллин урамы,
8а йорт адресы буенча урнашкан бина
фасадында мемориаль такта урнаштыру
турында

РСФСРның атказанган артисткасы, ТАССРның халык артисткасы, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Авзалова Әлфия Авзал кызы истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Казан шәһәре, Туфан Миңнуллин урамы, 8а йорт адресы буенча урнашкан йорт фасадында Авзалова Әлфия Авзал кызына татар һәм рус телләрендә түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турында тәкъдимен кабул итәргә:

«Бу йортта 2004 – 2017 елларда
күренекле татар җырчысы
Әлфия Авзалова яшәде

В этом доме в 2004 – 2017 гг.
жила выдающаяся татарская
певица Альфия Авзалова».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин